РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

Тел.:8(84364)2-63-02, факс:8(84364)2-63-04,e-mail:kukmor.kuk@tatar.ru,www:kukmor.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Карар**

25 март, 2025 ел №27

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең маневр торак фонды турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләрен һәм махсуслаштырылган торак урыннарына наемның типовой шартнамәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының «Торак урыннардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 14 маендагы 292/пр номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең маневр торак фонды турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче В.Н. Андреев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның «25» мартының 27 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең маневр торак фонды турындагы нигезләмә

(алга таба – Нигезләмә)

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары белән расланган Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләре һәм маневр фондының торак урынына наемның типовой шартнамәсе, РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының «Торак урыннардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 14 маендагы 292/пр номерлы боерыгы , Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең маневр торак фондының торак урыннарын (алга таба – маневр фонды) булдыру, бирү һәм алардан файдалану тәртибен билгели.

1.3. **Маневр фонды**ул – торак урыннары түбәндәгеләргә вакытлыча яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак фондының бер төре:

1) гражданнарга социаль наем шартнамәләре буенча үзләре били торган торак урыннары булган йортны капиталь ремонтлауга яисә реконструкцияләүгә бәйле рәвештә;

2) банк яисә башка кредит оешмасы кредиты исәбеннән сатып алынган әлеге торак урыннарга түләтүләр яисә юридик зат тарафыннан торак урын сатып алу өчен бирелгән максатчан заем акчалары исәбенә сатып алынган һәм, әгәр түләтү мөрәҗәгать ителгән вакытка мондый торак урыннар алар өчен бердәнбер булса, кредитны яисә максатчан заемны кире кайтаруны тәэмин итүгә салыну нәтиҗәсендә торак урыннарын югалткан гражданнарга;

3) бердәнбер торак урыннары гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз булган гражданнарга;

4) торак урыннары яшәү өчен яраксызга әйләнгән гражданнарга, шул исәптән күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану нәтиҗәсендә;

5) законнарда каралган очракларда башка гражданнарга.

1.4. Маневр фондының торак урыннары сыйфатында муниципаль торак фондының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә җавап бирә торган торак урыннары файдаланыла.

1.5. Маневр фонды Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының хокукый акты белән формалаштырыла һәм

әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә яшәүчеләргә вакытлыча яшәү өчен билгеләнә.

1.6. Маневр фондының торак биналары хосусыйлаштырылырга, алмашырга, читләштерелергә, арендага, поднаемга тапшырылырга тиеш түгел.

1.7. Торак урынны маневр фондына кертү өчен торак урыннарны маневр фондына кертү һәм күрсәтелгән фондтан төшерү Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары белән расланган Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртипне һәм таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.8. Муниципаль торак урыннарны маневр фондына кертеп, махсуслаштырылган торак фондына кертү турында тәкъдимнәр әзерләү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге торак комиссиясе, ведомство буйсынуындагы муниципаль предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.9. Маневр фондының торак урыннарын исәпкә алу Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.10. Маневр фондының торак урыннарына урнаштырылучы гражданнарны теркәү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.11. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мәсьәләләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә хәл ителә.

## 2. Маневр фондын формалаштыру тәртибе

2.1. Торак урынны, маневр фондына кертеп, махсуслаштырылган торак фондына кертү һәм күрсәтелгән фондтан торак урынны төшереп калдыру Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Маневр фонды түбәндәгеләр исәбеннән формалаштырыла:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль торак фондының бушаган торак урыннары;
- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә торак урыннар төзү яисә торак урыннар сатып алу.

## 3. Маневр фондыннан торак урын бирү нигезләре, шартлары һәм вакыты

3.1. Маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары белән расланган маневр фондының торак урынына наемның типовой шартнамәсе формасы буенча) түбәндәге вакытка төзелә:

1) йортны капиталь ремонтлау яисә реконструкцияләү тәмамланганчы (РФ Торак Кодексының 95 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән шундый шартнамә төзегәндә);

2) түләтү үтенече нәтиҗәсендә торак урыннарын югалткан гражданнар белән исәп-хисаплар тәмамланганчы, түләтү үтәлгән торак урыннарын сатканнан соң (РФ Торак Кодексының 95 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән шундый шартнамә төзегәндә);

3) бердәнбер торак урыны гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксызга әйләнгән гражданнар белән РФ Торак кодексында, башка федераль законнарда каралган тәртиптә исәп-хисаплар тәмамланганчы яисә аларга РФ Торак кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә дәүләт яки муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирелгәнче (РФ Торак кодексының 95 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән шундый шартнамә төзегәндә);

4) РФ Торак Кодексының 95 статьясының 3.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән исәп-хисаплар тәмамланганчы йә аларга торак урыннар бирелгәнче, әмма ике елдан да артыгракка түгел;

5) законнарда билгеләнгән (РФ Торак кодексының 95 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән шундый килешү төзегәндә).

3.2. Маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе төзелгән чорның узуы әлеге шартнамәне туктатуга нигез булып тора.

## 5. Маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча торак урыннар бирү тәртибе

4.1. Маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча маневр фондыннан торак урыны бирү турындагы мәсьәләне карау өчен, гражданнарга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

4.1.1. Гаиләнең барлык балигъ булган әгъзалары тарафыннан имзаланган шәхси гариза;

4.1.2. Гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документлар (паспорт яисә аны алмаштыручы башка документ);

4.1.3. Гариза бирүченең гаилә мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар (чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе);

4.1.4. Маневр фондына торак урын бирү шартларын раслый торган документлар:

гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә торак урынның яшәү өчен яраксыз хәлдә булу фактын раслый торган;

түләтү үтенече нәтиҗәсендә, түләтү үтәлгән торак урыннарын сатканнан соң, торак урыннарын югалту фактын раслый торган;

4.1.5. Гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының милкендә торак урыннары булу турындагы документлар (күрсәтелгән мәгълүмат ЕГРНда булмаганда);

4.1.6. Гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының торак урыннан файдалану хокукын расый торган документлар (күрсәтелгән документлар Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитетында булмаганда);

4.1.7. Гаиләнең барлык әгъзаларының маневр фондыннан торак урынга урнаштыруга язма ризалыгы һәм, маневр торак урынга наем шартнамәсе гамәлдә булган чор узгач, аны азат итү бурычы.

4.2. Күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы документларны, гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының күчемсез мөлкәтенә хокуклары турында ЕГРНнан өземтәне, Россия Федерациясе компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкларны, гариза бирүченең Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге муниципаль торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларны, маневр фондының торак урынын бирү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, йә дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы карамагындагы оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган башка документларны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитеты ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә ала.

4.3. Исәпкә алу (маневр фондының торак урыны бирү) турында гариза биргән гражданга документларны кабул итү хакында раслау кәгазе бирелә.

4.4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының гражданнарга маневр фондыннан торак урыны бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карары Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитетына гариза бирүче тапшырырга тиешле документлар тапшырылганнан соң иң кыска вакытта, әмма 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителгән булырга тиеш.

4.5. Түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының гражданнарга маневр фондыннан торак урыны бирүдән баш тарту турындагы карары кабул ителә:

1) гариза бирүче маневр фондыннан торак урыны бирү хокукына ия гражданнар категорияләренә керми;

2) дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының йә дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы оешманың ведомствоара соратуга җавабы маневр фондыннан торак урыны бирү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавын таныклый, әгәр тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз теләге белән тапшырылмаган булса, мондый органнар яки оешмалар карамагында мондый соратылган документ яки мәгълүмат булмау тиешле гражданнарның маневр фондыннан торак урыны алуга дәгъва кылу хокукын раслаган очраклардан тыш;

3) гарзиа бирүче әлеге Тәртипнең 4.1 п. нигезендә тапшыру бурычы гариза бирүчегә йөкләнгән документларны тапшырмаган.

1.9. Гражданнарга маневр фондыннан торак урыннары бирү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.7. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының гражданнарга маневр фондыннан торак урыннары бирү турындагы карары нигезендә «Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына

кертү кагыйдәләрен һәм махсуслаштырылган торак урыннарына наемның типовой шартнамәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары белән билгеләнгән типовой форма буенча маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе төзелә.

4.8. Маневр фондының торак бинаалары бер кешегә кимендә алты квадрат метр торак мәйданы исәбеннән бирелә.

## 5. Маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча торак урыннан файдалану

5.1. Маневр фондының торак урыныннан файдалану әлеге торак урында яшәүче гражданнарның, күршеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, санитария-гигиена, экология һәм законнарның башка таләпләрен исәпкә алып, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган торак урыннардан файдалану кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Яллаучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары маневр фондының торак урыннарыннан бары тик яшәү өчен генә файдаланырга, торак урынның сакланышын тәэмин итәргә һәм аны тиешле хәлдә тотарга тиеш.

5.3. Бер бүлмәдән (фатирдан) икенчесенә үз белдеге белән күчү, шулай ук маневр фондының торак урынына наем шартнамәсенә кертелмәгән затларны урнаштыру рөхсәт ителми.

5.4. Маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе торак законнарында каралган нигезләрдә туктатылган яисә өзелгән очракта, әлеге торак урыннарны биләүче гражданнар аларны маневр фондының торак урынына наем шартнамәсендә билгеләнгән срокта азат итәргә тиеш.

## 6. Маневр фондының торак урыныннан файдаланган өчен түләү

6.1. Маневр фондының торак урыннарына урнашкан гражданнар Россия Федерациясе законнарында һәм наем шартнамәсендә билгеләнгән тәртиптә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертергә тиеш.

6.2. Маневр фондында яшәүче гражданнар өчен торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләме гамәлдәге бәяләр һәм тарифлар буенча билгеләнә һәм муниципаль торак фондын социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылар өчен торак урыны өчен түләү күләменнән арта алмый.